ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

13. 02. 2019 г.Мензелинск № 138

«Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район халкын һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау һәм 2019-2021 елларга су объектларында иминлекне тәэмин итү” муниципаль максатчан программасын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 02.11.2013 елдагы “2014-2020 елларга Татарстан Республикасында су объектларында иминлекне һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау” дәүләт программасын раслау турында”гы №837 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының су объектларында булган хәлләрдән һәм табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән халыкка, икътисадка һәм табигый мохиткә салынган социаль, икътисадый һәм экологик зыянны минимальләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты

КАРАР ЧЫГАРА:

1. Беркетелгән «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район халкын һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау һәм 2019-2021 елларга су объектларында иминлекне тәэмин итү” муниципаль максатчан программасын расларга (алга таба – Программа).
2. Минзәлә муниципаль районының финанс-бюджет һәм җир-милек палатасына ел саен чираттагы финанс елына район бюджетын формалаштырганда мөмкинлекләрдән һәм Минзәлә муниципаль район бюджетыннан күрсәтелгән максатларга юнәлтелгән чаралардан чыгып, Программа чараларын тормышка ашыруга чараларны күздә тотарга.
3. Шәһәр һәм авыл җирлекләре башкарма комитетлары җитәкчеләренә, Минзәлә муниципаль районының оешма җитәкчеләренә, аларның нинди

хокукый формада булуларына карамастан, тиешле бюджет һәм бюджеттан тыш чыганаклар хисабыннан Программа чараларын вакытында башкарырга тәкъдим итәргә.

4.Гамәлдәге карар Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район Уставының 72 маддәсе нигезендә рәсми төстә басылырга тиеш.

5. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Минзәлә шәһәр башкарма комитеты Җитәкчесенә, Гадәттән тыш хәлләр комитеты рәисе Р.Ф.Ягафаровка йөкләргә.

Җитәкче К.Р.Нәҗмиев.

Минзәлә муниципаль район
Башкарма комитеты
Карары белән расланган
Дата_____ №

**“Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район халкын һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау һәм 2019-2021 елларга су объектларында иминлекне тәэмин итү”**
**муниципаль программасы**

**Программа паспорты**

| | |
|---|---|
| Программа атамасы | “Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район халкын һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау һәм 2019-2021 елларга су объектларында иминлекне тәэмин итү” (алга таба – Программа) |
| Программаны төп эшкәртүчеләр | Структур подразделениеләр, Минзәлә муниципаль район башкарма комитеты бүлекләре;<br>“Татарстан Республикасы буенча федераль янгынга каршы хезмәтенең 15 отряды” федераль дәүләт казна учреждениесе 122 янгын часте;<br>Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасындагы гражданнар оборонасы өлкәсендә вәкаләтләрне башкару бүлегенең (Минзәлә районы буенча) әйдәп баручы консультанты |
| Программаның максаты | Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы халкы, территорияләр һәм инфраструктура объектларының табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән сакланышын күтәрү, тискәре нәтиҗәләрне |

<table>
<tr><td></td><td>йомшарту; гражданнар оборонасы өлкәсендә чараларны тормышка ашыру; су объектларында халыкның иминлеген тәэмин итү</td></tr>
<tr><td>Программа бурычлары</td><td>1.Гражданнар оборонасы өлкәсендә идарә итүнең нәтиҗәлелеген күтәрү, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләү;</td></tr>
<tr><td></td><td>2. Минзәлә муниципаль районында кризиска каршы идарә итү системасын үстерү;<br>3. Халыкны гражданнар оборонасы өлкәсендә һәм гадәттән тыш хәлләрдә сакланырга әзерләү.</td></tr>
<tr><td>Программаның сроклары һәм башкару этаплары</td><td>2019-2021 еллар.</td></tr>
<tr><td>Программаның күләме һәм финанслау чыганаклары</td><td>Программаны финанслауның гомуми күләме <u>37 478,7 мең сум</u> тәшкил итә, шул исәптән,
<table>
<tr><th>Финанслау чыганагы</th><th>Барлыгы</th><th>2019 ел</th><th>2020 ел</th><th>2021 ел</th></tr>
<tr><td>Муниципаль район бюджеты</td><td>25 960,7</td><td>8 450,0</td><td>8 605,1</td><td>80905,6</td></tr>
<tr><td>Бюджеттан тыш чаралар (оешма акчалары һ.б.лар)</td><td>11 518,0</td><td>9 124,4</td><td>1 171,9</td><td>1 221,7</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>37 478,7</td><td>17 574,4</td><td>9 777,0</td><td>10 127,3</td></tr>
</table>
Искәрмә:<br>*финанслау күләме фараз характерында һәм Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| Программаны башкаруның көтелгән нәтиҗәләре (башкаруның нәтиҗәлелеге индикаторлары) | Программаны башкару түбәндәгеләрне тәэмин итү мөмкинлеге бирәчәк:<br>гадәттән тыш хәлләрне кисәтүгә һәм ликвидацияләүгә тулы күләмдә 100% матди резерв булдыру;<br>муниципаль район халкының билгеләнгән категориясен 100% ка тәэмин итү өчен шәхси саклану медицина чаралары һәм шәхси саклану чараларын туплау;<br>идарә итү, элемтә, мәгълүматлаштыру һәм хәбәр итү системаларынын, шулай ук кисәтү һәм ликвидацияләү өчен билгеләнгән чараларны һәм көчләрнең әзерлеге;<br>муниципаль район территориясендә гражданнар оборонасының саклану корылмаларын файдалануга даими хәзерлек торышында тоту;<br>гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу турында халыкка мәгълүмат бирү һәм хәбәр җиткерү;<br>халыкка тиешле ярдәм күрсәтү буенча чараларның нәтиҗәлелеген күтәрү максатларында, экстрен оператив хезмәтләрнең үз вакытында мәгълүмати аралашуы;<br>тормыш иминлеге культурасы мәсьәләләре буенча халыкны әзерләүне камилләштерү;<br>гидротехник корылмаларны (буаларны) авариясез эксплуатацияләү;<br>халыкны, иң беренче чиратта балаларны йөзү һәм сулыкларда коткару алымнарына, су объектларында үз-үзеңне куркынычсыз тоту күнекмәләренә әзерләү. |

**Программа хәл итәргә тиешле проблеманың характеристикасы**

Программа гражданнарны табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклану һәм халыкның су объектларында иминлеген саклану дәрәҗәсен күтәрүгә, гражданнар оборонасы бурычларын үтәүгә, халыкны, матди һәм мәдәни байлыкларны коткаруга һәм гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә зыян күргән халыкка ярдәм итүгә юнәлтелгән. Климатның глобаль үзгәрү процессында, хуҗалык эшчәнлеге яки эре техноген авария һәм катастрофалар нәтиҗәсендә табигый һәм техноген гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу мөмкинлеге Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы халкына һәм икътисадый объектларына сизелерлек куркыныч яный.

Әлеге программа гадәттән тыш хәлләр куркынычын киметү өлкәсендә идарә итү координациясе механизмнарын үстерүгә, кризислы һәм гадәттән тыш хәлләрдә экстрен эш итү системасын оптимальләштерүгә, шулай ук заманча мәгълүмати-коммуникацион технологияләрне һәм массакүләм мәгълүмат техник чараларын куллану нигезендә тормыш иминлеге культурасын формалаштыруга юнәлтелгән чараларны үз эченә ала.

Минзәлә муниципаль район территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы бар.

Табигый гадәттән тыш хәлләр язгы ташу, су басу, көчле җил, күп кар яву, корылык, урман янгыннары кебек куркыныч табигый күренешләр нәтиҗәсендә килеп чыгарга мөмкин.

Аеруча куркыныч объектлар техноген куркыныч тудыра.

Авария-коткару эшләре тормышка һәм әлеге эшләрне башкаручы кешеләр сәламәтлегенә янаучы факторлар белән характерлана һәм махсус әзерлек, экипировка һәм җиһазлану таләп итә.

Район коткару хезмәте үсешен саклау һәм муниципаль коткару формированиеләренең эшен башкаруга әзерлекне күтәрү, авария-коткару көчләрен тулысынча коралландыру проблемаларын программалы ысуллар белән хәл итәргә кирәк.

Гадәттән тыш хәлләрне һәм аның нәтиҗәләрен ликвидацияләүнең нәтиҗәлелеге күп очракта матди ресурларның булуы белән билгеләнә. Матди ресурсларның җитәрлек күләмдә булуы гадәттән тыш хәлне минималь срокларда локальләштерергә, аның нәтиҗәләре масштабын киметергә һәм иң мөһим мәсьәләне хәл итәргә – зыян күрүчеләрнең иң беренче чиратта тормышын коткарырга мөмкинлек бирә.

Номенклатура һәм матди ресурсларның резерв күләме фаразланган гадәттән тыш хәлнең ни дәрәҗәдә куркыныч булуыннан чыгып билгеләнә.

Әмма Минзәлә муниципаль район территориясендә фаразланган гадәттән тыш хәлләр куркынычыннан чыгып, әлеге резервлар гына җитми. Матди ресурслар белән тәэмин ителеш проблемасын тобәк дәрәҗәсендә хәл итәргә кирәк.

Зур масштаблы гадәттән тыш хәл килеп чыкканда, халыкны куркыныч районнардан вакытлыча урнаштыру пунктларына эвакуацияләү һәм зыян күрүчеләрнең беренчел яшәвен тәэмин итүне оештыру таләп ителә.

Эвакуация чараларын планлаштырганда, гадәттән тыш хәлләрдә зыян күргән халыкның беренчел яшәвен тәэмин итүне оештыруга муниципаль районның вазифаи затларының әзерлеген күтәрү буенча чаралар күрергә кирәк. Зур масштаблы гадәттән тыш хәлләрдә зыян күрүчеләрнең беренчел яшәвен тәэмин итү проблемаларын хәл итү өчен яңа карарлар кирәк.

Ике төрле билгеләнештә файдаланып булган социаль өлкәдәге объектларны тулысынча җиһазлау буенча программа чаралары тиешле проблемаларны чишү өчен максатка ярашлы дип күзаллана:

көндәлек режимда – социаль файдалы максатларда;

гадәттән тыш хәл режимында – зыян күрүчеләрнең беренчел яшәвен тәэмин итү.

Минзәлә муниципаль районында халыкның су объектларында һәлак булуының төп сәбәпләре түбәндәгеләр:

халыкның бу максатлар өчен җиһазланмаган урыннарда су коенуы;

алкоголь һәм наркотиклар кулланган хәлдә су коену яки сулыклар янында ял итү;

балаларның йөзә белмәве;

балаларның ата-аналардан башка су коенуы;

суда кеше тормышын саклау буенча кагыйдәләр белән билгеләнгән элементар нормаларны үтәмәү.

Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау һәм суда иминлеген тәэмин итү өлкәсендә югарыда күрсәтелгән проблемаларны хәл итү өстенлекле чаралар, аларны тормышка ашырганда эзлеклелекне билгеләүне һәм хакимиятнең барлык дәрәҗәләрен җәлеп итүне, шул исәптән муниципаль дәрәҗәдәге программалы ысуллар куллануны таләп итә.

## II. Максатлар, бурычлар, сроклар (этаплар) һәм Программа бурычларын хәл итү һәм максатларга ирешү күрсәткечләре (индикаторлар)

Программаның төп максаты:

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район халкының, территорияләрнең һәм инфраструктура объектларының табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклануын күтәрү, негатив нәтиҗәләрне йомшарту, гражданнар оборонасы өлкәсендә чараларны тормышка ашыру һәм су объектларында халыкның иминлеген тәэмин итү.

Программаның төп бурычлары:

1.Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләү өлкәсендә идарә итү нәтиҗәлелеген күтәрү;

2.Минзәлә муниципаль районында кризиска каршы идарә итү системасын үстерү;

3.Гражданнар оборонасы һәм агдәттән тыш хәлләрдә саклану өлкәсендә халыкны әзерләү;

4.Минзәлә муниципаль районы су объектларында халыкның иминлеген тәэмин итү.

Программага түбәндәге чаралар кертелгән:

халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау буенча;

су объектларында халыкның иминлеген күтәрү буенча;

оештыру һәм профилактик юнәлештә.

Шул ук вакытта күп кенә чаралар бу чор дәвамында башкарыла, ә кайберләре этаплап башкарылырга тиеш.

Һәр елның финанслау күләме Программаның алдагы ел чаралары нәтиҗәләре буенча төгәлләштереләчәк.

Программаны тормышка ашыру нәтиҗәләренә бәя бирү индикаторлары турында детальле мәгълүмат программага кушымтада өлешләп бирелгән.

Программаны тормышка ашыру сроклары: 2019-2021 еллар.

## III. Программа чаралары системасы

Программаның куелган төп максатларына һәм бурычларына ирешү өчен, 2019-2021 еллар чорында Программаның түбәндәге чараларын башкарырга кирәк:

муниципаль районда гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләүгә финанс резервларын формалаштыру һәм саклап тоту;

муниципаль район халкының билгеле категорияләрен тәэмин итү өчен индивидуаль саклану чараларын һәм индивидуаль саклану медицина чараларын туплау;

гражданнар оборонасының саклану корылмаларын куллануга даими хәзерлек торышында саклау;

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының төрле дәрәҗәдәге куркынычсызлык паспортларын эшкәртү һәм корректировкалау;
Республиканың Минзәлә муниципаль районының нефть һәм нефть продуктларының агуын кисәтү һәм ликвидацияләү буенча төрле дәрәҗәдәге планнарын эшкәртү;
гидротехник корылмаларның эксплуатацияләү ышанычлылыгын күтәрү буенча чаралар;
гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы турында халыкка экстрен хәбәр итүнең комплексла системасын булдыру һәм саклап тоту;
Минзәлә муниципаль районының Бердәм диспетчерлык хезмәтен булдыру һәм үстерү;
Минзәлә муниципаль район территориясендә гражданнар обронасы һәм гадәттән тыш хәлләр өлкәсендә укыту-консультация пунктлары эшчәнлеген оештыру, җиһазлау һәм булдыру;
халыкны, иң беренче чиратта балаларны, йөзәргә һәм суда коткару ысулларына өйрәтү;
су объектларында халыкның үз-үзен тотышы кагыйдәләре кергән листовка, памятка һәм плакатлар әзерләү һәм тарату;
Минзәлә елгасы ярында коткару вышкалары, пляж җиһазлары белән ике (төп һәм балалар өчен) пляж зоналарын төзекләндерү.

## IV. Программаны ресурслы тәэмин итүгә нигезләмә

Программаны финанслауның гомуми күләме **37 478,7 мең сум** тәшкил итә, шул исәптән,

| Финанслау чыганагы | Барлыгы | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел |
|---|---|---|---|---|
| Муниципаль район бюджеты | **25 960,7** | 8 450,0 | 8 605,1 | 80905,6 |
| Бюджеттан тыш чаралар (оешма акчалары һ.б.лар) | **11 518,0** | 9 124,4 | 1 171,9 | 1 221,7 |
| Барлыгы | **37 478,7** | 17 574,4 | 9 777,0 | 10 127,3 |

Искәрмә: *финанслау күләме фараз характерында һәм Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

Финанслау чыганаклары:
Минзәлә муниципаль район бюджеты: халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау буенча муниципаль озакка сузылган программаларны финанслауг, шул исәптән, гамәлдәге Программа кысаларында Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансферт алу өчен каралган чаралар (конкрет сумма күрсәтелмичә, мөмкин булган чыганак буларак фаразлана);
бюджеттан тыш чыганаклар: оешмалар, грантлар, инвесторлар чаралары һ.б.лар.
Программаны тормышка ашыруга финанс тәэмин ителеш законнарда билгеләнгән тәртиптә федераль, республика бюджетыннан, шулай ук Минзәлә муниципаль район бюджетыннан файдалануны күздә тота.
Программаны финанслауның гомуми күләме 37 478 700 (утыз җиде миллион дүрт йөз җитмеш сигез мең җиде йөз) сум тәшкил итә. Программаны тормышка ашыруның ресурслы тәэмин ителеше фаразлы характерда һәм Минзәлә муниципаль район бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертүне күздә тота.

## V. Программаны тормышка ашырудан социаль-икътисадый һәм экологик нәтиҗәләрнең нәтиҗәлелегенә бәя бирү

Программа социаль характерда, Минзәлә муниципаль районы халкын һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау торышы аның нәтиҗәлелегенең төп критерийлары булып тора.
Гамәлдәге Программаның максатлары нигезендә түбәндәге нәтиҗәләргә ирешү һәм тәэмин итү күздә тотыла:
гадәттән тыш хәлләрне кисәтүгә һәм ликвидацияләүгә тулы күләмдә матди резерв булдыру;
муниципаль район халкының билгеләнгән категориясен тәэмин итү өчен шәхси саклану медицина чаралары һәм шәхси саклану чараларын туплау;
идарә итү, элемтә, мәгълүматлаштыру һәм хәбәр итү системаларының, шулай ук кисәтү һәм ликвидацияләү өчен билгеләнгән чараларны һәм көчләрнең әзерлеге;
муниципаль район территориясендә гражданнар оборонасының саклану корылмаларын файдалануга даими хәзерлек торышында тоту;
гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу турында халыкка мәгълүмат бирү һәм хәбәр җиткерү;
халыкка тиешле ярдәм күрсәтү буенча чараларның нәтиҗәлелеген күтәрү максатларында, экстрен оператив хезмәтләрнең үз вакытында мәгълүмати аралашуы;
тормыш иминлеге культурасы мәсьәләләре буенча халыкны әзерләүне камилләштерү;

гидротехник корылмаларны (буаларны) авариясез эксплуатацияләү;

халыкны, иң беренче чиратта балаларны йөзү һәм сулыкларда коткару алымнарына, су объектларында үз-үзеңне куркынычсыз тоту күнекмәләренә әзерләү.

«Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район
халкын һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау
һәм 2019-2021 елларга су объектларында
иминлекне тәэмин итү” программасына
Кушымта

**«Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район халкын һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау һәм 2019-2021 елларга су объектларында иминлекне тәэмин итү” муниципаль максатчан программасы чараларын финанслауга һәм нәтиҗәләргә бәя индикаторлары, максат, бурычлары**

| тәртип№ | Чараның исеме | Башкаручылар | Башкару сроклары | Соңгы нәтиҗәгә бәя бирү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның билгесе | | | Финанс чыганагы | Финанслау күләме,мең сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |

**Максат: Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы халкы, территорияләр һәм инфраструктура объектларының табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән сакланышын күтәрү, тискәре нәтиҗәләрне йомшарту; граждannar оборонасы өлкәсендә чараларны тормышка ашыру;**
**1 нче бурыч. Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләү өлкәсендә идарә итүнең нәтиҗәлелеген күтәрү**

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.1 | Муниципаль районда гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләүгә финанс | Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты | 2019 - 2021 ел | Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләүгә резерв булдыру буенча чаралар | 100 % | 100 % | 100 % | муниципаль район бюджеты | 300,0 | 300,0 | 300,0 |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | чараларының резервын формалаштыру һәм саклап тоту | | | башкару | | | | | | |
| 1.2 | муниципаль район халкының билгеләнгән категориясен тәэмин итү өчен шәхси саклану медицина чаралары һәм шәхси саклану чараларын туплау; | Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты | 2019 - 2021 ел | Муниципаль берәмлектә, прдеприятиеләрдә һәм оешмаларда тупланган шәхси саклану чаралары һәм шәхси медицина саклану чаралары саны, данә | 150 данә | 350 данә | 564 данә | муниципаль район бюджеты | агымдагы эшчәнлек кысаларында | агымдагы эшчәнлек кысаларында | агымдагы эшчәнлек кысаларында |
| 1.3. | саклану корылмаларын файдалануга даими хәзерлек торышында тоту | Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты | 2019 - 2021 ел | Саклану корылмаларын файдалануга даими хәзерлек дәрәҗәсе | 100 % | 100 % | 100 % | муниципаль район бюджеты | 50,0 (2 подвалга) | 50,0 (2 подвалга) | 50,0 (2 подвалга) |
| | Гражданнар оборонасы | Оешмалар (килешенү буенча) | 2019 - 2021 ел | | | | | Бюджеттан тыш чыганаклар | 75,0 (3 подвалга) | 75,0 (3 подвалга) | 75,0 (3 подвалга) |
| 1.4. | Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының төрле дәрәҗәдәге куркынычсызлык паспортларын | Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты | 2019 - 2021 ел | муниципаль районның төрле дәрәҗәдәге куркынычсызлык паспортларын эшкәртү һәм корректировкалау дәрәҗәсе, | 100 % | 100 % | 100 % | муниципаль район бюджеты | агымдагы эшчәнлек кысаларында | агымдагы эшчәнлек кысаларында | агымдагы эшчәнлек кысаларында |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | эшкәртү һәм корректировкалау | | | процентларда | | | | | | | |
| 1.5. | Республиканың Минзәлә муниципаль районының нефть һәм нефть продуктларының агуын кисәтү һәм ликвидацияләү буенча төрле дәрәҗәдәге планнарын эшкәртү; | Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты | 2019-2021 ел | муниципаль районның нефть һәм нефть продуктларының агуын кисәтү һәм ликвидацияләү буенча төрле дәрәҗәдәге планнарын эшкәртүне тәэмин итү дәрәҗәсе; | 100 % | 100 % | 100 % | муниципаль район бюджеты | агымдагы эшчәнлек кысаларында | агымдагы эшчәнлек кысаларында | агымдагы эшчәнлек кысаларында |
| 1.6 | Гидротехник корылмаларны ышанычлы эксплуатацияләүне күтәрү буенча чаралар | Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты | 2019-2021 ел | Гидротехник корылмаларны (буаларны) авариясез эксплуатацияләү дәрәҗәсе, процентларда | 100 % | 100 % | 100 % | муниципаль район бюджеты | 607,3 | 607,4 | 607,4 |

**2 нче бурыч. Минзәлә муниципаль районында кризиска каршы идарә системасын үстерү**

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.1 | Гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы турында халыкка экстрен хәбәр итү комплекслы системасын | Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты | 2019-2021 ел | Башкарылган эшләр күләме, процентларда | 100% | 100% | 100% | муниципаль район бюджеты | 250,03 | - | - |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | булдыру һәм тоту | | | | | | | | | | |
| 2.2 | Минзәлә муниципаль районында бердәм диспетчерлык хезмәтен тоту һәм үстерү | Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты | 2019-2021 ел | Билгеләнгән бурычларны башкару буенча әзерлек дәрәҗәсе,процентларда | 100% | 100% | 100% | муниципаль район бюджеты | 1462,3 | 1523,2 | 1580,6 |

**3 нче бурыч. Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдән саклану өлкәсендә халыкны әзерләү**

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.1 | Минзәлә муниципаль районында гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр өлкәсендә укыту-консультация пунктларын булдыру, җиһазлау, эшчәнлеген оештыру | Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты | 2019-2021 ел | Булдырылган укыту-консультация пунктларының әзерлек дәрәҗәсе, процентларда | 100% | 100% | 100% | муниципаль район бюджеты | агымдагы эшчәнлек кысаларында | агымдагы эшчәнлек кысаларында | агымдагы эшчәнлек кысаларында |

**4 нче бурыч. Су объектларында халыкның иминлеген тәэмин итү**

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4.1 | Халыкны, иң беренче чиратта балаларны йөзү һәи суда коткару алымнарына өйрәтү | Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты | 2019-2021 ел | Балалар һәм үсмерләр спорт мәктәпләрендә йөзргә өйрәнүче балалар саны. Кеше. | 271 | 271 | 271 | муниципаль район бюджеты<br><br>бюджеттан тыш | 5620,4<br><br>1049,4 | 5812,6<br><br>1096,9 | 6027,7<br><br>1146,7 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | чаралар | | | |
| 4.2 | Су объектларында халыкның үз-үзен тоту кагыйдәләре булган листовка, памятка, плакатларны әзерләү һәм тарату | Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты | 2019-2021 ел | Башкарылган эшләр күләме, процентларда | 100% | 100% | 100% | муниципаль район бюджеты | 10,0 | 12,0 | 15,0 |
| 4.3. | Минзәлә елгасы ярында коткару вышкалары, пляж жиһазлары куелган ике пляж зонасы (төп һәм балалар өчен) төзекләндерү | Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты | 2019-2021 ел | Башкарылган эшләр күләме, процентларда | 100% | 100% | 100% | муниципаль район бюджеты<br><br>бюджеттан тыш чаралар | 150,0<br><br>8 000,0 | 300,0<br><br>50,0 | 300,0<br><br>50,0 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Программа буенча барлыгы, шул исәптән, чаралар:** | **17 574,4** | **9 777,0** | **10 127,3** |
| **муниципаль район бюджетыннан** | **8 450,0** | **8 605,1** | **8 905,6** |
| **Бюджеттан тыш чыганаклардан** | **9 124,4** | **1 171,9** | **1 221,7** |